Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

29 июнь, 2020 ел № 8

**Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 12 һәм 15 статьялары, РФ Хөкүмәтенең «Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йортта торак урыннарын һәм гомуми милекне яраклаштыру чаралары турында» 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары нигезендә, инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).
2. Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль Комиссия турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак фонды составына керә торган, инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми милекне, инвалидларның ихтыяҗларын һәм аларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүне исәпкә алып, яраклаштыру буенча чаралар планын расларга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: Ф.Х.Гарифуллина

2020 елның 29 июнендәге 8 номерлы карарга
1 нче кушымта

ИНВАЛИДЛАРНЫҢ ИХТЫЯҖЛАРЫН ИСӘПКӘ АЛЫП ЯРАКЛАШТЫРУ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ИНВАЛИДЛАР ӨЧЕН ФАЙДАЛАНА АЛЫРЛЫК БУЛУЫН ТӘЭМИН ИТҮ МАКСАТЛАРЫНДА ИНВАЛИДЛАРНЫҢ ТОРАК УРЫННАРЫН ҺӘМ ИНВАЛИДЛАР ЯШИ ТОРГАН КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРДА ГОМУМИ МИЛЕКНЕ ТИКШЕРҮ БУЕНЧА МУНИЦИПАЛЬ КОМИССИЯ СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Гарифуллина Ф.Х. | - | Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы |
| Файзрахманов В.Ф. | - | Ятмас-Дусай авыл җирлеге ветераннар Советы Рәисе (килешү буенча) |
| Билалова Р.А. | | Ятмас-Дусай авыл җирлегенең инвалидлар Советы Рәисе |
| Галиев Н.Г. | | Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы депутаты(килешү буенча) |
| Файзрахманов А.В. | - | Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |
| Идиятов М.М. | - | Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |
| Фатихов А.М. | | Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча) |

2020 елның 29 июнендәге 8 номерлы карарга 2 нче кушымта

# ИНВАЛИДЛАРНЫҢ ИХТЫЯҖЛАРЫН ИСӘПКӘ АЛЫП ЯРАКЛАШТЫРУ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ИНВАЛИДЛАР ӨЧЕН ФАЙДАЛАНА АЛЫРЛЫК БУЛУЫН ТӘЭМИН ИТҮ МАКСАТЛАРЫНДА ИНВАЛИДЛАРНЫҢ ТОРАК УРЫННАРЫН ҺӘМ ИНВАЛИДЛАР ЯШИ ТОРГАН КҮПФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРДА ГОМУМИ МИЛЕКНЕ ТИКШЕРҮ БУЕНЧА МУНИЦИПАЛЬ КОМИССИЯ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль торак фонды составына, шулай ук шәхси торак фондына кергән, аларны инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында, инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр яши торган һәм алар даими яшәү өчен файдаланыла торган торак биналарны һәм күрсәтелгән торак урыннары урнашкан күпфатирлы йортлардагы (алга таба – инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлар) гомуми милекне тикшерү үткәрүне оештыру комиссиясенең эш тәртибен билгели.

Инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча муниципаль комиссия (алга таба – Комиссия) инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, аларны яраклаштыру һәм инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү эшен оештыру өчен төзелде.

1.2. Комиссия «Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йортта торак урыннарын һәм гомуми милекне яраклаштыру чаралары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары белән расланган таләпләр нигезендә инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидлар өчен фадалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча эшчәнлекне координацияләүне гамәлгә ашыручы даими эшләүче коллегиаль орган булып тора (алга таба – Кагыйдәләр).

1.3. Комиссия Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре, Комиссия әгъзалары составында төзелә.

1.4. Комиссия вәкаләтләре тулысынча Кагыйдәләр белән билгеләнә.

1.5. Комиссия составы Ятмас-Дусай авыл җирлеге карары белән раслана.

1.6. Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне тикшерү (алга таба – тикшерү) инвалидның торак урынын һәм инвалид яши торган күпфатирлы йортта гомуми милекне, инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итү максатларында, шулай ук, мондый бинада яшәүче затның инвалидлыгы белән бәйле, тормыш эшчәнлегендәге чикләүнең үзенчәлекләренә карап, инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып, аларны яраклаштыру мөмкинлеген бәяләү максатларында гамәлгә ашырыла, шул исәптән, түбәндәгеләр аркасында туган чикләүләр:

а) кресло-коляска куллану ихтыяҗы белән бәйләнгән хәрәкәт итү функциясенең нык бозылуы;

б) ярдәмче чараларны куллану кирәклеге белән бәйле ишетү функциясенең нык бозылуы;

в) проводник-этне куллану зарурлыгы белән бәйле күрү функциясенең нык бозылуы;

г) үсештә тоткарлыклар һәм кеше организмы функцияләренең башка бозылулары.

1.7. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Хөкүмәте норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына һәм муниципаль хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
2.1.1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең вәкилләре комиссия составына кергән җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы дәүләт күзәтчелеге органнары, юридик затлар һәм башка оешмалар белән компетенция кысаларында үзара хезмәттәшлекне тәэмин итү.
2.1.2. Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча эшчәнлекне координацияләү
2.2. Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:
2.2.1. Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне тикшерү.
2.2.2. Гамәлдәге законнар нигезендә тикшерү актларын рәсмиләштерү.
2.2.3. Инвалид яши торган күпфатирлы йортны төзекләндерүнең икътисадый максатчанлыгы (максатсызлыгы) турында карар кабул итү.
2.2.4. Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру мөмкинлеге яки мөмкинлеге булмау турында бәяләмә чыгару.

## 3. Комиссиянең хокуклары һәм бурычлары

3.1. Үз бурычларын тормышка ашыру өчен, Комиссия хокуклы:
3.1.1. Билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан, вазыйфаи затлардан һәм гражданнардан Комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле материалларны, документларны һәм мәгълүматны соратырга һәм алырга.
3.1.2. Комиссия эшендә катнашу өчен аңа карата тикшерү үткәрелә торган инвалид яши торган күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, оешмалар вәкилләрен җәлеп итәргә.
3.1.3. Комиссия утырышына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми милекне тикшерүдә катнашучы федераль органнарның вәкаләтле вәкилләрен һәм башка затларны чакырырга.
3.2. Комиссиянең вазифалары:
3.2.1. Комиссия рәисе:
- Комиссия утырышларында рәислек итә;
- Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;
- Комиссиянең чираттагы утырышын үткәрү датасын, вакытын һәм урынын билгели;
- Комиссия утырышының көн тәртибен раслый;
- Комиссиянең урынбасарлары һәм башка әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;
- башкарма хакимиятнең кызыксынган федераль органнарында Комиссияне тәкъдим итә;
- Комиссия утырышлары беркетмәләренә имза сала.

Комиссия рәисе булмаганда, аның вазифаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.
3.2.2. Комиссия секретаре:
- гражданнардан, оешмалардан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан кергән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып, Комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра;
- Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышын үткәрү датасы һәм урыны һәм карала торган мәсьәләләр турында хәбәр итүне гамәлгә ашыра;
- Комиссия утырышына кирәкле материалларны Комиссия әгъзаларына җибәрүне оештыра;
- Комиссия утырышлары беркетмәләрен төзи;
- Комиссия әгъзаларына һәм вәкаләтле органнарга Комиссия утырышлары беркетмәләрен җибәрүне гамәлгә ашыра;
- Комиссия рәисе кушуы буенча башка вазыйфаларны башкара.
3.2.3. Комиссия әгъзалары:
- дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан, вазыйфаи затлардан һәм гражданнардан Комиссияне гамәлгә ашыру өчен кирәкле материаллар, документлар һәм мәгълүматны сораталар һәм билгеләнгән тәртиптә алалар;
- инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урыны, гомуми милекнең характеристикалары турындагы документларны (техник паспорт (техник план), кадастр паспорты һәм башка документларны) карыйлар;
- гражданны инвалид дип тану турындагы документларны, шул исәптән инвалид дип танылган гражданга медик-социаль экспертиза актыннан өземтәләрне карый;
- инвалид яши торган күпфатирлы йортта гомуми милекне визуаль, техник карау үткәрәләр, кирәк булганда, өстәмә тикшерүләр, торак бинаның конструкцияләрен сынныйлар;
- торак бинаны һәм/яки гомуми милекне яраклаштыру карата конкрет ихтыяҗларны ачыклау максатыннан, инвалид дип танылган гражданнар белән әңгәмәләр үткәрәләр;
- инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм/яки гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итү зарурлыгын һәм мөмкинлеген бәялиләр;
- Комиссия рәисе күрсәтмәләрен үтиләр;
- Комиссия утырышларына материаллар әзерләүдә катнашалар;
- Комиссия утырышларында катнашалар, ә Комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, Комиссия секретаренә карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язмача тапшыралар, ул Комиссия утырышында игълан ителә һәм Комиссия карарына теркәлә;
- Комиссия кабул иткән карар белән килешмәгән очракта, язма рәвештә үзләренең аерым фикерләрен белдерәләр;
- Комиссия карарларын үтәү өчен кирәкле чараларны күрәләр.
Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен башка затларга бирергә хокуклы түгел.

## 4. Комиссиянең эш тәртибе

4.1. Тикшерү инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидлар өчен уңайлы шартлар тәэмин итүгә яраклаштыру буенча чаралар планы нигезендә үткәрелә һәм үз эченә түбәндәгеләрне ала:
- инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урыны, гомуми милекнең характеристикалары турындагы документларны (техник паспорт (техник план), кадастр паспорты һәм башка документларны) карау;
- гражданны инвалид дип тану турындагы документларны, шул исәптән инвалид дип танылган гражданга медик-социаль экспертиза актыннан өземтәләрне карау;

- инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын, гомуми милекне визуаль, техник карау, кирәк булганда, өстәмә тикшерүләр, торак бинаның әйләнүче конструкцияләрен сынаулар үткәрү;
- торак урынында яшәүче инвалид дип танылган граждан белән, әлеге гражданның торак урынын яраклаштыру карата конкрет ихтыяҗларын ачыклау максатларында, әңгәмә үткәрү;
- инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итү зарурлыгына һәм мөмкинлегенә бәя бирү.
4.2. Комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә.
Комиссия әгъзаларына һәм чакырылган затларга Комиссия уздырыла торган көнгә кадәр кимендә өч көн алдан электрон яки почта элемтәсе аша хәбәр ителә.
4.3. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, хокуклы була.
Комиссия карарлары Комиссия комиссия әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, Комиссия әгъзалары үзләренең аерым фикерен язмача белдерергә һәм аны Комиссия карарына кушарга хокуклы.
Комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, Комиссия секретаренә карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен үз вакытында язмача тапшыралар, ул Комиссия утырышында игълан ителә һәм Комиссия карарына теркәлә.
4.4. Тикшерү нәтиҗәләре буенча инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итү максатларында инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милеген тикшерү акты Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 23 ноябрендәге 836/пр номерлы боерыгы (алга таба – тикшерү акты) белән расланган тикшерү акты формасы буенча рәсмиләштерелә, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:
- инвалидның торак урынының һәм гомуми мөлкәтнең тикшерү нәтиҗәләре нигезендә төзелгән характеристикаларын тасвирлау;
- Кагыйдәләрнең III һәм IV бүлекләрендә каралган таләпләр исемлеге арасыннан инвалидның тикшерелгән торак урыны һәм/яки гомуми милек туры килми торган таләпләр (мондый туры килмәүләр ачыкланса);
- инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы гомуми милекнең тикшерү нәтиҗәләре нигезендә төзелгән характеристикаларын тасвирлау;
- инвалидның ихтыяҗларын һәм аның инвалид файдалана алырлык булуын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне яраклаштыру зарурлыгы булу яки булмавы турында Комиссиянең дәлилле нигезләнгән нәтиҗәләре;
- иинвалидның ихтыяҗларын һәм аның инвалид файдалана алырлык булуын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм (яки) гомуми милекне яраклаштыру өчен техник мөмкинлек булу яки булмау турында Комиссиянең дәлилле нигезләнгән нәтиҗәләре;
- инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итү буенча чаралар исемлеге.
4.5. Комиссиянең эш нәтиҗәсе булып инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итүгә яраклаштыру яки мондый мөмкинлекнең булмавы турында бәяләмә тора. Тиешле бәяләмәләрнең формалары Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана.

4.6. Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып һәм инвалидка файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә яраклаштыру мөмкинлеге турындагы бәяләмә Комиссия тарафыннан тхбәндәгеләр нигезендә чыгарыла:
а) тикшерү акты;
б) инвалид яши торган күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен), инвалидның торак урынын һәм (яки) инвалид яши торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы шартларын тәэмин итү максатларында, реконструкцияләүнең яисә капиталь ремонтлауның икътисадый максатчанлыгы турында Кагыйдәләрнең 17 пунктындагы «а» пунктчасында каралган Комиссия карары.
4.7. Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итү мөмкинлеге булмау турында бәяләмә инвалидның торак урынын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә инвалид яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигез булып тора.
4.8. Комиссия утырышын үткәрү нәтиҗәләре буенча биш эш көне эчендә беркетмә төзелә. Беркетмәгә утырышта катнашкан барлык Комиссия әгъзалары имза сала.
4.9. Чараларны тиешле муниципаль программага кертү турында карар кабул итү өчен Кагыйдәләрнең 19 пунктында каралган бәяләмә, аны чыгарганнан соң 10 көн эчендә раслау өчен Комиссия тарафыннан муниципаль берәмлек башлыгына җибәрелә.

**5. Комиссия карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү тәртибе**

5.1. Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарларга яисә гамәл кылуга (гамәл кылмауга) шикаять бирү юлы белән судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин. Мондый шикаять әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә карала.
5.2. Комиссиянең гамәленә (гамәл кылмавына) яисә карарына карата шикаять үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:
- гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять бирелә торган карар кабул иткән Комиссиянең исеме;
Гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүмат яисә гариза бирүче юридик затның атамасы, аның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номер(-лар)ы, гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (булган очракта) һәм почта адресы;
- Комиссиянең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында белешмәләр;
- гариза бирүче Комиссия карары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) белән килешми торган дәлилләр. Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.
5.3. Гариза бирүче шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алырга хокуклы.
5.4. Судка кадәр шикаять бирү процедурасын башлап җибәрү өчен нигез булып Ятмас-Дусай авыл башкарма комитетына почта аша җибәрелгән яисә гариза бирүче тарафыннан язмача кәгазьдә яки гариза бирүче тарафыннан гариза бирүченең Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында мәҗбүри авторизацияләнүен күздә тоткан мәгълүмати-коммуникацион технологияләр чараларын кулланып җибәрелгән шартта электрон документ формасында тапшырылган шикаять керү тора.
5.5. Ятмас-Дусай авыл җирлеге башкарма комитетына кергән шикаять, гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән

баш тартуга яки мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга шикаять белдерелгән очракта, аны теркәгәннән соң утыз календарь көн эчендә карап тикшерелергә тиеш.
5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:
- шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, карар кабул итү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү формасында;
- шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.
5.7. Әгәр мөрәҗәгатьтә мөрәҗәгатьне җибәргән гариза бирүченең фамилиясе, җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, мөрәҗәгать җавапсыз кала.
Әгәр мөрәҗәгать тексты укыла торган булмаса, мөрәҗәгатькә җавап әзерләнми, бу хакта аны җибәрүче гариза бирүчегә, аның фамилиясе һәм почта адресы укыла торган булса, хәбәр ителә.
Комиссия компетенциясенә керми торган мәсьәләләр булган язма мөрәҗәгатьләр аларны теркәгән көннән җиде көн эчендә тиешле органга яисә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү аның компетенциясенә керә торган тиешле вазыйфаи затка җибәрелә, гариза бирүчегә мөрәҗәгатьнең башка адреска җибәрелүе турында хәбәр ителә. Бу карар турында гариза бирүчегә язмача хәбәр ителә.
Телдән мөрәҗәгатьләр һәм җаваплар телефон аша булганда, вәкаләтле вазыйфаи зат җентекләп, тиешле норматив-хокукый актларга сылтама белән мөрәҗәгать итүчеләргә үзләрен кызыксындырган сораулар буенча мәгълүмат бирә. Телефон шалтыратуына җавапта телефон шалтыратуын кабул иткән затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм вазыйфасы турында мәгълүмат булырга тиеш.
Вәкаләтле вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм милкенә зыян китерү куркынычы булган яисә мәсхәрәле гыйбарәләр булган мөрәҗәгатьләр аларда куелган сорауларның асылы буенча җавапсыз кала.
5.8. Карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача яки гариза бирүче теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

2020 елның 29 июнендәге 8 номерлы
карарга 3 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯТМАС-ДУСАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ТОРАК ФОНДЫ СОСТАВЫНА КЕРӘ ТОРГАН, ИНВАЛИДЛАР ЯШИ ТОРГАН КҮП ФАТИРЛЫ ЙОРТЛАРДАГЫ ИНВАЛИДЛАРНЫҢ ТОРАК УРЫННАРЫН ҺӘМ ГОМУМИ МИЛЕКНЕ, ИНВАЛИДЛАРНЫҢ ИХТЫЯҖЛАРЫН ҺӘМ АЛАРНЫҢ ИНВАЛИДЛАР ӨЧЕН ФАЙДАЛАНА АЛЫРЛЫК БУЛУЫН ТӘЭМИН ИТҮНЕ ИСӘПКӘ АЛЫП, ЯРАКЛАШТЫРУ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ПЛАНЫ

| № т/б | Чара атамасы | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Муниципаль торак фонды составына кергән, аларны инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында, инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр яши торган һәм алар даими яшәү өчен файдаланыла торган торак биналарны (алга таба –инвалид яши торган торак бина) һәм шулай ук күрсәтелгән торак урыннары урнашкан күпфатирлы йортлардагы (алга таба – инвалид яши торган күпфатирлы йорт) гомуми милекне тикшерү өчен кирәкле гражданнардан гаризалар һәм документлар кабул итү | Кирәк булганда (гариза буенча) | Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү максатларында инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда гомуми милекне тикшерү буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) |
| 1.1 | Гражданны инвалид дип тану турындагы документларны, шул исәптән инвалид дип танылган гражданга медик-социаль экспертиза актыннан өземтәләрне (алга таба – гражданны инвалид дип тану турында документлар) карау | Гражданны инвалид дип тану турында ведомствоара комиссиягә документлар кергәннән соң 15 көн эчендә | Ведомствоара комиссия |
| 1.2 | Инвалидның торак урыны, инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы гомуми милекнең характеристикалары турындагы документларны (техник паспорт (техник план), кадастр паспорты һәм башка | Гражданны инвалид дип тану турында ведомствоара комиссиягә документлар кергәннән соң 15 көн эчендә | Ведомствоара комиссия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | документларны) карау | | |
| 2 | Тикшерү үткәрү: | | |
| 2.1 | Инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын, гомуми милекне визуаль, техник карау, кирәк булганда, өстәмә тикшерүләр, торак бинаның әйләнүче конструкцияләрен сынаулар үткәрү | Ведомствоара комиссиягә инвалидның торак урыны характеристикалары һәм гражданны инвалид дип тану турында документлар кергән көннән алып 30 көн эчендә | Ведомствоара комиссия |
| 2.2 | Торак урынны яраклаштыруга карата конкрет ихтыяҗларны ачыклау максатларында, торак урынында яшәүче инвалид дип танылган граждан белән әңгәмә үткәрү | Ведомствоара комиссиягә инвалидның торак урыны характеристикалары һәм гражданны инвалид дип тану турында документлар кергән көннән алып 30 көн эчендә | Ведомствоара комиссия |
| 2.3 | инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итү зарурлыгына һәм мөмкинлегенә бәяләү. | Ведомствоара комиссиягә инвалидның торак урыны характеристикалары һәм гражданны инвалид дип тану турында документлар кергән көннән 45 көн эчендә | Ведомствоара комиссия |
| 2.4 | инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итү максатларында инвалид яши торган күпфатирлы йортта инвалидның торак урынын һәм гомуми милеген тикшерү актын әзерләү (алга таба – тикшерү акты) | Ведомствоара комиссиягә инвалидның торак урыны характеристикалары һәм гражданны инвалид дип тану турында документлар кергән көннән 45 көн эчендә | Ведомствоара комиссия |
| 3 | Инвалид яши торган күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен), инвалидның торак урынын һәм (яки) инвалид яши | Ведомствоара комиссиягә инвалидның торак урыны | Ведомствоара комиссия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы шартларын тәэмин итү максатларында, реконструкцияләүнең яисә капиталь ремонтлауның икътисадый максатчанлыгы/ максатка яраксыз булуы турында Комиссия карарын кабул итү | характеристикалары һәм гражданны инвалид дип тану турында документлар кергән көннән алып 60 көн эчендә | |
| 4 | Инвалидның торак урынын һәм инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып һәм инвалидка файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә яраклаштыру мөмкинлеге/ мөмкинлек булмау турында бәяләмә чыгару | Ведомствоара комиссиягә инвалидның торак урыны характеристикалары һәм гражданны инвалид дип тану турында документлар кергән көннән алып 60 көн эчендә | Ведомствоара комиссия |
| 5 | Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгына инвалидның торак урынын һәм инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып һәм инвалидка файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә яраклаштыру мөмкинлеге турында бәяләмә (алга таба — бәяләмә) җибәрү | Нәтиҗә чыгарганнан соң 10 көн эчендә | Ведомствоара комиссия |

Искәрмә: әлеге Планның 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән чаралар тикшерү актында күпфатирлы йортның (йортның бер өлешенең) гамәлдәге һәм киртәләп торучы конструкцияләрен үзгәртмичә, аны үзгәртеп кору яки капиталь ремонтлау юлы белән инвалидның торак урынын яраклаштыру инвалидның торак урынын һәм/яки инвалид яши торган күпфатирлы йортта гомуми милекне инвалидның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру һәм аларның инвалидка уңайлы булу шартларын тәэмин итү мөмкинлеге булмау турында нәтиҗә булган очракта гамәлгә ашырыла.